Республика Татарстан
Совет Старомензелябашского
сельского поселения Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлеге
Советы

---

РЕШЕНИЕ
2024 ел 23 ноябрь

КАРАР
№ 22а

Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш
авыл җирлеге Советының
«Физик затлар мөлкәтенә салым турында»
10.11.2014 ел, № 15
карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, Сарман муниципаль районының «Иске Минзәләбаш авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 10.11.2014 ел, № 15 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

А) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә

«2. Салым ставкаларын күләмендә билгеләргә:

2.1. 0,1 процентка карата:

2.1.1. Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2 бүлегендә күрсәтелгән салым салу объектларында урнашкан гаражлар һәм машина урыннары, шул исәптән;

2.1.2. һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше алып бару өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яисә корылмалары;

2.2. 0,2 процентка карата:

2.2.1. фатирлар, фатир өлешләре;

2.2.2. бүлмә;

2.3. 0,3 процентка карата:

2.3.1. торак йортлар, торак йортларның өлешләре;

2.3.2. төзелеп бетмәгән объектларның проектлана торган билгеләнеше торак йорт булган очракта;

2.3.3. составына бер генә булса да торак йорт кергән Бердәм күчемсез комплекслар;

2.4. 2 процент:

2.4.1. Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектлары;
2.4.2. Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектлары;
2.4.3. һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектлары;
2.4.4. 2025-2027 еллар чорына 1,2 процент, 2028 елда һәм аннан соңгы елларда – гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән урыннарга карата салым салу объектларына карата 2 процент, Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган;
2.5. Башка салым салу объектларына карата 0,5 процент.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» халыкка җиткерергә (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлеге
Советы рәисе — А.Н.Габдрахманов